ҖИМЕРҮНЕ ҖИҢҮ

Төрнәстә сөт эшкәртү заводы ачылды

> 2

КЫЗЫКЛЫ ДӘРЕС

Казан мәктәпләре укытучылары татар телен укытуга заманча алымнар кертә

> 3

ТРАНСПОРТ САЛЫМЫ:

ташламалардан ничек файдаланырга

> 3

ТӨРЛЕ БӨТЕНЛЕК

Татарстан үзенең күптөсмерлелеге белән бай

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 170 (28752) | Сишәмбе | 23 ноябрь | 2021 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

ЯБЫК ИШЕКЛӘР

ТАТАРСТАНДА ҖӘМӘГАТЬ ТРАНСПОРТЫНА QR-КОДСЫЗ КЕРТМИ БАШЛАДЫЛАР

Үзем күрдем

«QR-коды булмаганнарга керү тыела». Татарстанда әлеге язу җәмәгать транспорты ишекләрендә дә пәйда булды. Яңа кагыйдәне тиз генә кабул итәргә теләмиләр. Тикшерүчеләрнең дә, тикшертүчеләрнең дә хәле җиңелләрдән түгел. Шәһәр транспортындагы кодлы тормышны «ВТ» хәбәрчесе дә күреп кайтты.

Билгеле булганча, хәзер 18 яше тулганнар җәмәгать транспортында вакцинацияне тулысынча узгач һәм коронавирус белән авырып сихәтләнгәч бирелә торган QR-код яки коронавируска каршы вакцина ясатырга ярамаганлыкны раслаучы белешмә (медотвод) булган очракта гына йөри ала. Шәһәр яны һәм шәһәрара транспортта кодны – билетлар сатканда, шәһәр транспортында бусагадан атлап керүгә яки хәрәкәт вакытында тикшерәләр. Әлеге кагыйдә метрода йөрүчеләргә дә кагыла. Аларны да билет алганчы, турникетлар янында тикшерәләр.

Автобус тукталышына чыгып басканда, иртәнге сәгать җиде тулып киткән иде инде. Көн дә бер вакытта килә торган троллейбусның уты да күренмәде. Иртәнге сәгатьләрдә җәмәгать транспорты хәрәкәтенең 30 минутка акрынаюы турында соңрак укып белдек. «QR-коды булмаганнарга керү тыела». Троллейбус ишегендәге әлеге язу күренүгә, тизрәк шул «серле шакмаклар»ымны эзләргә керештем. Бу кабалану юкка була язды: һәр кеше янында өчәр-бишәр минут басып торып тикшерү үткәрүче олы яшьтәге кондуктор, янына үзем килмәсәм, мине, гомумән, игътибарсыз калдырасы иде. Шуннан файдаланыпмы икән, код күрсәтү түгел, билет алмаучылар да юк түгел. Кайберәүләр моңа җиңелчәрәк караса да, мәсьәлә җитди ул үзе. Код тикшерүчеләрне контрольдә тоту өчен Татарстанда махсус мобиль төркемнәр булдырылган. Алар җәмәгать транспортында QR-коды булмаган кешене ачыкласа, тикшерүчегә беркетмә тутырачаклар. Кондукторларның эшен җиңеләйтү максатыннан, шәһәрнең 65 тукталышында QR-кодны транспорт предприятиеләре хезмәткәрләре тикшерәчәк. Бу хакта Татарстанның АТП ассоциациясе рәисе Сергей Темляков хәбәр итте.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Вакцина ясатуымны раслаучы кодны күрсәткәч, кондуктордан аны тикшерү тәртибен сорадым. «Кодны тикшерү өчен махсус телефон өләштеләр. Әллә мин аңлап җиткермим, әллә техникасында җитешсезлекләр бар – тикшерү күп вакытны ала», – диде ул.

Шәһәр буйлап «сәяхәт»емне дәвам итәр өчен, башка маршрут буенча баручы автобуска утырдым. Кеше аз булгангадырмы, бу юлы кодны керә-керешкә сорадылар. Ләкин монда да проблемасыз булмады – код тикшерә торган телефон көйсезләнде. Болай да кәефе шәптән булмаган кондуктор апаның тәмам ачуы чыкты шуңа. Янымда утырып баручы кыз иркенләп йөртә торган хикмәтле кодны алырга өлгермәгән икән. Билгеле булганча, ике компонентлы прививканың беренчесен генә ясатсаң, җәмәгать транспортында йөрү хокукы бирелми. Ләкин кондуктор кызны куып чыгарырга ашыкмады. «Пассажирларны да кызганам. Ләкин үзәккә җиткән-дәрәк чыгуларын үтенмичә булмый – анда тикшерәләр», – диде ул.

Маршрутымны кабат үзгәртеп, тагын бер автобустагы хәлләрне белешергә булдым. Анда исә кондуктор: «Мин бу эш белән шөгыльләнергә тиеш түгел», – дип кырт кисте.

> **Рөстәм МИҢНЕХАНОВ, Татарстан Президенты:**
> – Транспортта чирне бик тиз йоктырырга мөмкин. Әлбәттә, кешеләр мондый яңалыкларга төрлечә карый, әмма бездә башка вариантлар юк. Бу юлдан киткән илләрдә коронавируска кагылышлы вазгыять тотрыклана инде. Өлкән кешеләр куркыныч аеруча янаган төркемгә керә, чөнки алар коронавирусны бик авыр кичерә. Шуңа күрә мөмкин булганча сакларга тырышабыз. Әмма безне алар арасында вакцина ясату күрсәткеченең түбән булуы борчый – нибары 49% кына. Ковид бүлекләрендә дәваланучыларның күбесе – өлкән яшьтәге кешеләр. Үлем очракларының да 85 проценты аларга туры килә.

Ахыры 3 нче биттә >

Сан

Республика халкының 44 проценты эш урыннарына җәмәгать транспортында бара. Әлеге санны «HeadHunter» сервисы үткәргән сораштыру мәгълүматлары раслый. Бу исә – Россия төбәкләре арасында иң түбән күрсәткечләрнең берсе. Сораштыруда катнашучыларның яртысы эшкә машинада, ә 15 проценты оешмаларда каралган махсус транспортта килә икән. Һәр унынчы кеше эшкә җәяү йөрүен әйткән.

Төзекләндерү эшләре төгәлләнә

Республикада социаль-мәдәни өлкә объектларын төзекләндерү буенча республика программаларын гамәлгә ашыру төгәлләнеп килә. Быел бездә 3,5 мең корылманы төзекләндерүгә 23 миллиард сумнан күбрәк акча бүлеп бирелгән. Бүгенгә барлык программалар буенча эшләр 96 процентка төгәлләнгән. Хөкүмәт йортында Рөстәм Миңнеханов уздырган киңәшмәдә төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры Марат Айзатуллин шундый саннар китерде. Мәгариф өлкәсендә (413 объект керә) балалар бакчаларын капиталь төзекләндерү эшләре дәвам итә әле. 48е инде әзер. Хастаханәләргә килсәк, төзекләндерү программасына кертелгән 18 объектның дүртесендә әлегә эшләр төгәлләнмәгән. Бу өлкәдә төзекләндерү эшләре 93 процентка үтәлгән. Эчке эшләр министрлыгы карамагындагы биналарны тәртипкә салу программасы 94 процентка хәл ителгән. Спорт корылмаларын төзекләндерү программасы буенча эшләр дә төгәлләнеп килә. Әлегә 16 корылма файдалануга тапшырылган. Ә инде инженерлык корылмаларын яңарту буенча барлык 6 программа тулысынча тормышка ашырылган.

Теләк – бер, ә чынбарлык?

Россиядә яшәүчеләр, пенсиянең уртача күләме 43 мең сум булса әйбәт, дигән фикердә. Узган елдагы белән чагыштырганда, күрсәткеч 8 процентка арткан. SuperJob хезмәте үткәргән сораштыру нәтиҗәләре шундый. Тикшеренүдә барлыгы 32 мең кеше катнашкан. Респондентларның 24тән яшьрәкләре, аена 35,8 мең сумлык пенсия тормыш алып барырга җитә, дип күрсәтсә, 45 яшьтән өлкәнрәкләрнең күпчелеге, 45 мең сумнан да ким булмавы кирәк, дип белдергән. Зур шәһәрләрдә яшәүчеләр арасында пенсиягә чыкканнан соң эштән китәргә теләүчеләр азрак.

Казанда яшәүчеләр үзләрен 41,9 мең сумлык пенсиягә лаек дип саный. Сораштыруда катнашучыларның 34 проценты пенсиягә чыккач та эшен дәвам иттерергә теләвен искәрткән. Һәр 5 респондентның берсе (19 процент) төп керем чыганагы сыйфатында – пенсиясен, 15 проценты – саклык акчасын һәм 6 проценты дәүләтнеке булмаган пенсия фондындагы акчасын атаган. Сораштыру нәтиҗәләреннән күренгәнчә, Татарстан башкаласында яшәүчеләр саклык акчасына – азрак, пенсиягә чыккач эшләү мөмкинлегенә күбрәк исәп тота башлаган. Ике ел эчендә шәһәрдә лаеклы пенсиягә ихтыяҗ 16 процентка арткан: 2019 елда 36 мең сум булса, 2021 елда бу сан 41,9 мең сумга җиткән.

Яңа елга өйләренә кайталар

Чаллы мэры Наил Мәһдиев газ шартлаудан зыян күргән йортта төзекләндерү-яңарту эшләрен тикшергән. Йортның дүртенче һәм бишенче катлары заманча стандартлар буенча төзекләндерелә. Шәһәр башлыгы шартлаудан зыян күрүчеләргә Яңа елны үз фатирларында каршы алу мөмкинлеге тудыру бурычын куйган. «Төзүчеләрнең эшенә сүз әйтерлек түгел, әмма әле мактарга да иртәрәк. Декабрь ахырында гына йомгак ясарга мөмкин булачак», – дип искәрткән Мәһдиев. Хәзер 1970–1980 елларда куелган чуен батареяларны заманча җылыткычларга алыштыру эшләре башланган. Зыян күрүчеләр яңа обойлы, яңа ишек-тәрәзәле, яңа җиһазлы фатирларга керәчәк.

Шәһәр мэры әйтүенчә, яңарту эшләрен башлап җибәрүгә шәһәр бюджетыннан 10 миллион сум бирелгән. Тагын чама белән 70–80 миллион сум өстәп бирелә. Бу суыткычлар, телевизор, йорт җиһазлары сатып алуга тотылачак. Моннан тыш шартлаган йортта яшәүчеләрнең югалган милке өчен республика бюджетыннан акча бүлеп бирeләчәк.

Көн кадагында

Беркатлылык бәһасе

Ни гаҗәп, акчага бәйле бер-бер хәл булса, кеше уяулыгын югалта. Моннан исә кырыгалдарлар бик оста файдалана. Хәйлә юлларын табып, телефон аша кешеләрне төп башына утырткан мошенникларны гына алыйк. Саннарга карасаң, тел шартлатырлык: 2020 елда Россия халкының матди югалтулары 66 млрд сум белән исәпләнә.

Быелгы саннар да моннан ким булмастыр, чөнки беренче яртыеллыкта мошенниклыкның 80 проценты нәкъ тә телефоннан алдаучыларга туры килгән.

Ярык тагарак алдында калучылар Татарстанда да җитәрлек. Әле менә шушы көннәрдә булган бер очракны гына карыйк. 15 ноябрьдә Чаллының бер предприятиесендә эшләүче өч хезмәткәргә җитәкчеләреннән смс-хәбәр килгән. Хәбәрдә – сылтама, хезмәт хакын алу өчен шуңа керергә, банк исәп-хисап мәгълүматларын язарга кирәк, имеш. Хезмәткәрләр, билгеле, җитәкче кушканнарны үтәгән. Әмма хезмәт хакы алу урынына, аларның картасыннан 50 мең сумлап акча юкка чыккан. Зыян күрүчеләр әлеге күңелсез хәл турында полициягә гариза язган. Хокук саклау органнары «җитәкче»нең номеры Дагыстанда теркәлгән булуын ачыклаган.

Сентябрь аенда Казанда яшәүче 84 яшьлек пенсионер әби дә, кырыгалдарлар хәйләсенә ышанып, шактый күләмдә акчасын югалткан иде. Үзен банк хезмәткәре дип таныштырган берәү шалтырата аңа. Барыбыз өчен дә билгеле сүзләрне кабатлый: картага мошенниклар һөҗүме ясалган, янәсе. Соңрак әбинең номерына полиция хезмәткәре исеменнән тагын берәү шалтыратып, банк вәкиле сүзләренең дөрес булуын раслаган. Моңа өстәп, әлеге хәл турында беркемгә дә сөйләмәскә кушкан. Кырыгалдарлар күрсәтмәсе буенча, пенсионер әби акчасын «ышанычлы» исәп-хисап номерына җибәрә. Шулай итеп, ике атна дәвамында 5 млн сум акчасын «ышанычлы» кулларга тапшырып торган ул.

Ни өчен телефон мошенникларының хәйлә кармагына хәтта бу хакта белгән кешеләр дә эләгә соң?

«Джет инфосистемалары» компаниясенең мошенниклыкка каршы көрәш бүлеге башлыгы Алексей Сизов сүзләренчә, кырыгалдарлар ике факторга таянып эш итә. Аның берсе – булачак корбан турында мәгълүмат, икенчесе – сөйләшү өчен сайланган вакыт.

Белгеч сүзләренчә, караклар электрон почта яки компьютерга вирус кертеп, шәхси мәгълүматны ала алган очракта, акчаны югалту ихтималы аеруча зур. Андый вакытта мошенникларның сүзләре дә ышандырырлык яңгырый, ди.

Сөйләшү вакыты да мөһим: мошенникларның активлыгы җомга кичендә һәм ял көннәрендә аеруча арта. Белгеч аңлатуынча, бу вакытта банкларның шикле операцияләргә оператив җавап бирә торган хезмәткәрләре азрак була.

Сүз уңаеннан, Россия Икътисади үсеш министрлыгы «Элемтә турында»гы Законны үзгәртү өчен закон проекты әзерләде. Ул телефон мошенниклыгына каршы көрәшкә билгеле бер өлеш кертәчәк, дип ышаналар. Закон проекты нигезендә, банкларга элемтә хезмәтеннән файдаланучыларның мәгълүматлары җибәреләчәк. Әлбәттә, абонент моңа үзе риза булса гына. Мошенниклар шалтырата калса, моның шикле шалтырату булуын кулланучы алдан беләчәк дигән сүз.

Сүзгә-сүз

Вячеслав ВОЛОДИН, Россия Дәүләт Думасы Рәисе:

Юлларда хулиганлык өчен җәзаны катгыйландыру турында сөйләшергә ниятлибез. Социаль челтәрләрдә танылу, язылучылар санын арттыру өчен узышлар оештыруны булдырырга ярамый. Юл хәрәкәте кагыйдәләрен берничә мәртәбә бозган кешеләргә карата җәзаны катгыйландыруны дөрес дип саныйбыз. Транспорт чарасын тартып алу тәкъдимен дә җиткерәчәкбез.

(«Телеграм» социаль челтәрендәге шәхси сәхифәсеннән)

БУРЫЧКА АКЧА БИРӘСЕЗМЕ?

«Синергия» университеты сораштыруы нәтиҗәләренә караганда, Россиядә яшәүчеләрнең өчтән икесе үз гомерендә бер генә тапкыр булса да бурычка акча биреп торган. Сораштыруда катнашучыларның 47,4 проценты, 5 мең сумнан да артыграк акча биргәнем юк, дип белдергән. Респондентларның 39,3 процентының беркайчан да әҗәткә акча биргәне юк икән.

КЕМНӘР ЕШРАК БУРЫЧКА АКЧА СОРЫЙ?



Туган-тумачалар	44,5%
Дуслар	26,5%
Таныш-белешләр	13,7%

Кисәк суыта

Татарстанда кинәт кенә суыта. Моннан тыш синоптиклар республикада яшәүчеләрне юлларның тайгак булачагы турында кисәтә. Иртәгә төнлә 11–16 градуска кадәр суыта. Көндез 7–12 градус салкын, урыны белән кар. Пәнҗешәмбе көнне бераз җылыта: көндез +1...–6, төнлә 7–12 градус салкын. Кар-буран булырга мөмкин.

kzn.ru

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

КАРА ТӘНЛЕЛӘР ГОМЕРЕ КЫЙММӘТЛЕ

Планетада үткән атнада да күңелсез хәлләрнең кара спирале бөтерелде. Париж, Рим, Брюссель, Роттердам, Вена – Европаның барлык башкалаларында һәм шәһәрләрендә протест дулкыны тынмый, көчәя. Күп кенә очракларда эш кул сугышларына кадәр барып җитә, полиция көчләренең җитешмәве үзен сиздерә.

Әмма хәбәрләрнең яхшысы һәм сөендерә торганы да очраштыргалый. Япониядән коронавируска бәйле өметләндергеч хәбәр алынды. Анда пандемиянең бишенче дулкыны көчле һәм дәһшәтле булып башланган иде, кисәк кенә тукталды. Кояш чыгышы илендә күптән түгел генә бер көнгә 26шар мең авыру йоктыру очраклары теркәлә иде. Хәзер чирләүчеләр саны бер көнгә 200дән дә артмый. Бу уңайдан генетиклар «дельта» штаммының үз-үзен юк итә башлавы турында белдерү ясадылар. Россия галимнәре арасында да озакламый коронавирус көчсезләнәчәк һәм куркыныч тудырмый башлаячак дигән фикерне алга сөрүчеләр күренә. Мантыйкый рәвештә ул шулай булырга тиеш тә иде инде. Урта гасырларда котырынган чума эпидемиясе дә ничек кинәт пәйда булса, шундый ук кинәтлек белән тына торган булган.

Пандемиянең тукталу ихтималы сөендерә, әлбәттә. Күңел моның шулай булуын көтә һәм тели. Әмма планетадагы социаль киеренкелек ковидка гына бәйле түгел. АКШта соңгы көннәрдә хәл кискенләште. Анда Трамп идарә иткән вакытта ук башланган BLM хәрәкәте (black lives matter – кара тәнлеләрнең гомере әһәмияткә ия) гыйсъянчылык утын яңа дәрәҗәдә дөрләтергә омтыла башлады. Якшәмбегә каршы төндә кара тәнлеләр фетнәсе Нью-Йоркта Бруклин урамыннан зур ташкын булып узды, «Һәрбер шәһәрне тулысынча яндыр!» – дигән шигарьләр кычкырдылар. Фетнә давылы бөтен ил буйлап көчәя. Вазгыятьнең кисенләшүе Кайл Риттенхаус исемле ак тәнле яшь егетнең судта аклануы белән бәйле. Үткән елның августында Висконсин штатының Кеноша шәһәрендә кара тәнле Джекоб Блейк исемле адәм полицейский тарафыннан атып яралангач, афроамерикалылар бар нәрсәне җимерә һәм тетә башлап, урам йөрешләренә чыкканнар иде. Америкада бит хәл хәзер шундыйрак: кара тәнлеләр ни кыланса да, аларга тияргә ярамый. Кайл исемле егет шул чакта, полициягә тәртип урнаштыруда ярдәм итү нияте белән, Иллинойстан Кеношага килгән. Кулында законлы рәвештә сатып алынган винтовкасы булган. Урамда үзенә афроамерикалылар һөҗүм иткәч, үз-үзен саклау өчен ике кешене атып үтергән. Аны шунда ук кулга алып хөкем итәргә әзерләнделәр. Суд гаепләү карары чыгарса, егеткә гомерлек төрмә җәзасы тиеш иде, әмма казыйлар Кайлны аклады. Егетнең үз-үзен сакларга хокукы бар дип таптылар. Андый карарны Америкада берәү дә көтмәгән иде, чөнки вазгыять шундый: кара тәнлегә мылтык төбәсәң генә дә, катгый җәзага тартыласың. Суд карары BLM хәрәкәтенә яңа ялкын өстәде. Үткән елларда кара тәнлеләр зур протест башлап җибәрергә әзерләнделәр. Шәһәрләрдә, аерым алганда, Портлэндта полиция «тәртипсезлекләр режимы» кертте. Яңа урам сугышларына әзерлек башланды. Үзен демократия һәм гаделлек эталоны дип танытырга яраткан АКШ держава булудан туктауга таба юл тота.

Россиядә

БУЛЛИНГКА КАРШЫ ЗАКОН

Россиядә дә тормыш планетадагы гомуми вазгыять белән бәйле рәвештә ага, билгеле. Бездә дә, башка илләрдәге кебек үк, проблемалар үзләренә чишелеш көтә. Аларның күпчелеге икътисади хәлнең катлаулануына бәйле. Ашламалар дефициты фонында бу төр товарны базар мөнәсәбәтләре кысасыннан чыгарырга ниятлиләр. Тармакны дәүләт үз көйләве астына алырга җыена: бәяләрнең күпме буласын, кая күпме ашлама озатасын чиновниклар хәл итә башлаячак, диләр. Югары технологияләр флагманы булып саналган «Роснано» дефолт бусагасында тора, облигацияләр буенча әҗәтләрен түли алмый, дигән хәбәр дә килеп иреште. Кызыл уылдыкка бәя рекордлы рәвештә күтәрелгән: килосы 5 мең сумга җиткән. Әле ике-өч көн элек кенә газета хәбәрчесенең бер танышы, килосы 4 мең сумнан уылдык алып кайтып бирәм, дип торган иде. 2000 елның октябрендә кызыл уылдык бәясе килога 675 сум булган. Шуннан чагыштырыгыз инде темпларны. Уылдык бирә торган балыкны тоту артуга карамастан, бәя күтәрелә.

Менә мондый икътисади фон социаль киеренкелекне арттыра инде, билгеле. Шөкер, алга киткән Көнбатыш илләреннән аермалы буларак, бездә масштаблы протест юк. Әмма милләтләр белән милләтләр арасында каршылыкны көчәйтергә теләүчеләр җитәрлек. Үзара кешелек мөнәсәбәтләрендә дә кытыршылыклар җитәрлек. Дәүләт Думасы, шул мәсьәләләрне хәл итү кыен булган проблемага әйләндермәс өчен, профилактик законнар эшләү белән мәшгуль соңгы көннәрдә. Әле менә яңа гына, дүшәмбе иртәсендә, матбугат чараларында җинаятьчеләрнең милләтен атауны тыя торган канун проектының Думага кертелүе хакында хәбәр иттеләр. Проектны Чечня Республикасы парламенты тәкъдим итә. Депутатларның яңа закон проектына мөнәсәбәте әлегә мәгълүм түгел.

Икенче бер канун проекты – уку йортларындагы буллингка (балаларның бер-берсен кимсетүе һәм читкә тибәрүе) каршы закон белән инде депутатларның махсус эш төркеме шөгыльләнә. Укытучыга дәүләт хезмәткәре статусы бирү, конфликтка кергән якларны килештерү белән шөгыльләнүче махсус хезмәт булдыру, дошманлашучы якларның үзара очрашуын булдырмау өчен мәктәптән мәктәпкә күчерү – канун проектында менә шундый чаралар исемлеге бар икән. Дәүләт Думасының мәгариф буенча комитеты рәисе урынбасары Яна Лантратова: «Буллинг темасы соңгы елларда җәмәгатьчелекне дулкынландыра, ә закон юк», – ди. Әлегә мәсьәләнең ачык һәм аңлаешлы чишелешләре күренмәвен дә таный. «Буллингны тыярга» дип язып куеп кына мәсьәлә хәл ителмәвен дә әйтә. Эшкә белгечләрнең зур төркемен җәлеп итәргә ниятлиләр. Проблеманың барлыгын тану – аны хәл итүгә беренче адым инде, билгеле, әмма катлаулы вазгыятьне хәл итәргә тиешле закон ничек килеп чыгар – анысын киләчәктә күрербез, мөгаен.

РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ:
«ПАНДЕМИЯ ЭЛЕКТРОН СӘҮДӘГӘ ЮЛ АЧТЫ»

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов халык белән очрашу барышында Чаллыда эшмәкәрләрнең сорауларына җавап бирде. Президент коронавирус пандемиясенең бизнес өчен җитди сынау булуын, әмма эшчәнлекнең кайбер төрләре өчен аның үзенчәлекле үсеш ноктасына әйләнүен әйтте.

tatarstan.ru

– Авыр заманда яшибез, пандемия әлегәчә бетмәде. Нинди генә карар булмасын, без бизнеска азрак зыян салуны күздә тотып эш итәбез, тик әлегә бу эзсез узмый. Әмма мондый шартларда чәчәк аткан бизнес төрләре дә бар. Әгәр пандемия булмаса, электрон сәүдә итү беркайчан да яхшы нәтиҗәләргә ирешә алмас иде, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Үз чиратында Татарстан Президенты каршындагы Эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил, бизнес-омбудсмен Фәрит Габделганиев республика җитәкчесе белән эшкуарлар очрашуының мөһим булуын билгеләп үтте.

– Нәтиҗәләр буенча хакимият органнарына йөкләмәләр бирелә, закон актларына төзәтмәләр кертелә, өстәмә ярдәм программалары кабул ителә, – диде ул.

Мисалга ул Питрәч районында электрон сәүдә өлкәсе вәкилләре белән очрашуны китерде.

– Нәтиҗәдә узган атнада «2021–2022 елларга Татарстанда интернет-сәүдә үсеше программасы» кабул ителде. Ул Татарстан эшмәкәрләре өчен сату базарларын киңәйтүгә һәм республиканың алдынгылыгын ныгытуга юнәлдерелгән, – диде Фәрит Габделганиев.

Очрашуда Татарстанның дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры урынбасары Альберт Яковлев әйтүенчә, «Минем субсидияләр» кушымтасы ел ахырына кадәр тагын 36 ярдәм төре белән тулыланачак.

– Бүгенгә платформа эшли, 19 ярдәм төре тормышка ашырылган. Инде 4,5 мең кеше әлеге кушымтаны телефоннарына күчереп алды. 54 меңнән артык гариза каралган һәм 300 млн сумлык ярдәм күрсәтелгән. Ел ахырына кадәр тагын 36 ярдәм чарасын кертү планлаштырылган. Һәм алар арасында иң көтелгәне – эшмәкәрләргә микрозаем бирүдә күрсәтелә торган ярдәм, – дип хәбәр итте Альберт Яковлев.

Бизнес-омбудсменның иҗтимагый вәкиле Михаил Кузнецов сүзләренә караганда, эшмәкәрләрнең күпчелеге ярдәм чараларыннан актив файдалана. Ләкин кайбер төрләре кәгазь документларда теркәүне таләп итә.

– Мәсәлән, субсидияләр. Аның шартлары буенча, кем тизрәк гариза тапшыра, шул субсидия алырга дәгъва кыла ала. Тик бу бит Казандагы һәм башкалага якын районнардагы эшмәкәрләргә уңайлырак шартлар тудыру булып чыга, – ди Михаил Кузнецов.

Аның фикеренчә, әгәр барысы да электрон рәвештә эшләнсә, уңышлы булыр иде. Рөстәм Миңнеханов әлеге мәсьәләнең мөһимлегенә басым ясады. Аның сүзләренчә, республикада инде шәхси хуҗалыклар өчен субсидия гаризаларын онлайн җыю системасы тәҗрибәсе бар.

– Әлеге эшне ахырга кадәр җиткерә алмавыбыз өчен безгә оят булырга тиеш. Шуңа күрә моның өчен нәрсә эшләргә кирәклеген билгеләп бетерергә кирәк, – диде Президент һәм электрон төргә беренче чиратта күчерергә мөмкин булган ярдәм чараларын ачыкларга кушты.

Шул ук вакытта Рөстәм Миңнеханов Россия хөкүмәтенә эшмәкәрләр өчен микрозаем вакытын озынайту тәкъдиме белән чыгарга әзер булуын да белдерде. Михаил Кузнецов әйтүенчә, микрозаем – мөһим булган ярдәм чарасы. 2020 елда чикләүләр кертелгәнчегә кадәр Ярдәм фонды бирә торган микрозаем вакыты 3 ел иде. Хәзер федераль үзәк карары буенча ул нибары ике елга гына калдырылды. Михаил Кузнецов бу вакытны биш елга кадәр озайтырга тәкъдим итте.

– Эшләячәкбез. Уен кагыйдәләрен үзгәртү бик матур түгел, – диде Рөстәм Миңнеханов, аңа җавап итеп. – Бу вакытта (коронавирус аркасында чикләүләр булганда) заемны ике елга түгел, киресенчә, 4 елга бирергә кирәк. Бу – чыннан да, бик дөрес сорау. Без дә хөкүмәткә мөрәҗәгать итәргә әзер. Һич югы 3 елны кире кайтарырга кирәк.

Президент әле күптән түгел генә тәмамланган Халык санын исәпкә алу турында да фикерен белдерде. «Республикабыз җәлеп итәрлек булсын. Барыбыз да шуның өчен тырышырга тиеш. Бөтен җирдә халык саны кими, бездә исә үсеш бар. Димәк, безгә киләләр, барысының да Татарстан ягына таба хәрәкәт итәсе килә», – диде ул.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

Өч елда төзелгән 8,5 млрд сумлык завод. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов «Алабуга» махсус икътисади зонасында яңа завод ачылышында катнашты.

Әлеге завод углерод сүсе алу өчен чимал җитештерәчәк. Яңа завод өчен «Росатом» дәүләт корпорациясе – 5,2 млрд, «Алабуга» – 3 млрд, Россия Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы 0,3 млрд сум акча бүлеп биргән. «Бу завод ачылу белән Россиядә композит материаллар җитештерү чылбыры тәгалләнде. Хәзер без беркемгә дә бәйле түгел. Бу – безнең республика өчен дә, ил өчен дә әһәмиятле вакыйга», – диде республика җитәкчесе һәм әлеге объектны сафка бастыруда катнашкан һәркемгә рәхмәтен җиткерде.

Ачылыш тантанасында видеоэлемтә аша Россия Премьер-министры Михаил Мишустин да котлау сүзләрен җиткерде. Аның әйтүенчә, Алабугада углерод сүсен җитештерү буенча юнәлешне үстерү алга таба Россиянең авиатөзелеш һәм башка тармак ихтыяҗларын канәгатьләндерәчәк.

* * *

Моннан тыш «Алабуга» махсус икътисади зонасында Президент рәислегендәге Күзәтчелек советының чираттагы утырышы узды. Совет әгъзалары утырышның көн тәртибенә куелган мәсьәләләр, шул исәптән Күзәтчеләр советы составындагы үзгәрешләр турында фикер алышты. Моннан тыш, «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисади зонасын үстерүнең планы тәкъдим ителде.

* * *

Рөстәм Миңнеханов Чаллыдагы «Мастер» Кама индустриаль паркы территориясендә стеклопакетлар җитештерүче «СтиС-Чаллы» заводының эшчәнлеге белән танышты. Завод 3500 квадрат метрдан артык территориядә урнашкан һәм сәнәгатьнең барлык тармаклары өчен сыйфатлы продукция җитештерергә мөмкинлек бирә торган иң яңа заманча җайланмалар белән җиһазландырылган җитештерү линиясен үз эченә ала.

* * *

М-7 «Идел» трассасыннан Ижауга һәм Пермьгә китә торган юлны төзекләндергәннән соң кабат ачтылар. 11 чакрым озынлыктагы юл Менделеевск районының өч торак пункты аша уза. Төзекләндерү эшен быелның маенда башлаганнар. «Бу катлаулы, авария куркынычы булган участок иде. Капиталь ремонт кысасында полосалар саны икедән дүрткә җитте. Шулай ук биредә юлларны киңәйтү буенча яңа технологияләр сынап каралган, аннан соң алар ил күләмендә кулланылачак», – диде Рөстәм Миңнеханов.

* * *

Татарстан Президенты «КАМАЗ-Мастер» командасы спортчылары һәм җитәкчелеге белән очрашты. Полигонда Рөстәм Миңнехановка К5 кабинасы базасында ясалган яңа буын спорт йөк машиналарын күрсәттеләр, һәм ул яңа автомобильне шәхсән үзе сынап карады. «Бу – бөтенләй башка автомобиль, – диде ул К5 моделе турында. – «Дакар» ярышлары алдыннан очрашу, техниканы тикшерү гадәте бар. Ел саен җитди үзгәрешләр күрәбез. Бу – бөтен команданың тырышлыгы. Яңа автомобильдәге үзгәрешләр көндәшлеккә сәләтле. Барысы да эшләнгән. Барыгызга да рәхмәт! Бөтен ил «КАМАЗ-Мастер» командасы өчен җан атачак».

Йолдызлы Алекно

Казанның Волейбол үзәгендә танылган тренер Владимир Алекноның дан йолдызы барлыкка килде. Бу уңайдан узган тантанада Татарстан Дәүләт Советы Рәисе, республиканың Волейбол федерациясе президенты Фәрит Мөхәммәтшин да катнашты.

Фәрит Мөхәммәтшин Владимир Алекноның Россия волейболы үсешенә зур өлеш кертүен һәм Казан «Зенит»ының зур җиңүләрен әйтте. «Алекно баш тренер булып эшли башлагач, безнең команда илдә иң яхшыларның берсенә әверелде, – диде ул. – Волейбол профессиональ спортчылар, студентлар һәм мәктәп укучылары, эре предприятиеләр хезмәткәрләре һәм авыл районнары халкының, гомумән, Татарстанда яшәүчеләрнең яраткан спорт төренә әйләнде».

Танылган тренерны шулай ук Татарстан Президенты Аппараты җитәкчесе, Татарстандагы «Динамо» физик культура һәм спорт җәмгыяте Советы рәисе Әсгать Сәфәров, «Зенит-Казан» волейбол клубы президенты Рәфкать Кантюков та тәбрикләде. «Безнең барлык уңышларыбыз һәм җиңүләребез – уртак тырышлык, спорт һәм волейболга тугрылык нәтиҗәсе», – дип җавап кайтарды Владимир Алекно.

Россиянең атказанган тренеры, «Зенит-Казан» һәм Россия җыелма командаларының элеккеге баш тренеры Владимир Алекно Татарстан башкаласында эшләгәндә барлыгы 31 ярышта җиңү яулады. Казан командасы аның җитәкчелегендә 650дән артык очрашуда чыгыш ясады. Казан Волейбол үзәге музеенда моңа кадәр Игорь Шулепов, Сергей Тетюхин, Ллойл Болл, Дмитрий Фомин, Руслан Олихвер һәм Метью Андерсонның дан йолдызлары ачылган иде.

ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ДЕПУТАТЛАРЫ ИГЪТИБАРЫНА

Алтынчы чакырылыш Татарстан Дәүләт Советының егерме җиденче утырышы 25 ноябрьдә (10.00 сәгатьтә башлана) Дәүләт Советы утырышлар залында үткәрелә.

Дәүләт Советы депутатларын теркәү Дәүләт Советы бинасында 25 ноябрьдә 8.00 сәгатьтә башлана. **Белешмәләр алу өчен телефон: 267-63-62.**

ҖИМЕРЕЛГӘННЕ ҖИҢҮ

Терлекчелек

Россиядә иң күп сөт җитештерүче Татарстанда эре инвесторларда гына түгел, шәхси һәм фермер хуҗалыкларында да ел әйләнәсендә төп керем чыганагы – сөт җитештерүдән. Белгечләр әйтүенчә, тәүлегенә 4 мең тоннага якын продукция җитештерүче хуҗалыклардагы сөтне тулы күләмдә эшкәртеп сатканда, керем бермә-бер күбрәк булыр иде. Тик бу юнәлештә эшлисе дә эшлисе шул әле.

Татарстан авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Ленар Гарипов әйтүенчә, бернинди кыенлыкларга карамыйча, республика хуҗалыкларында савым сыерларының баш саны арта. Соңгы елларда Мамадыш районында үсеш – 4589, Әтнә районы хуҗалыкларында – 3412 баш, Балтач хуҗалыкларында савым сыерларын 1988 башка арттыра алганнар.

Нурлат якларына эш сәфәре белән баргач, район җитәкчесе Алмаз Әхмәтшин белән дә шул турыда сөйләшеп алдык. Кайчандыр гөрләп эшләп торган Нурлат сөт комбинаты банкротлыкка чыккач, хуҗалыклар үз продукцияләрен күрше төбәкләргә сата башлаган. Кызык бит: сөтне чагыштырмача арзан бәядән алучылар берничә көннән шул ук продукцияне эшкәртеп, бәясен ике-өч тапкыр арттырып, нурлатлыларга китереп сата. Никадәрле салым, эш урыннары, башка төрле керем югала.

Районга җитәкче булып килгәч тә, Алмаз Әхмәтшин үз эшчәнлеген моңарчы дистә еллар дәвамында таралып, җимерелеп барган биналарда җитештерү мәйданнары ачу буенча махсус программа булдыруга юнәлтә. Шундыйларның берсе – Төрнәс авылындагы сөт эшкәртү предприятиесе. Бу эшкә алынырга теләк белдерүче инвесторлар да табыла.

– Район хуҗалыкларында җитештерелгән сөтнең 90 процентка якыны чит өлкәләргә сатыла иде. Хуҗалык җитәкчеләре белән сөйләшү-киңәшү нәтиҗәләреннән күренгәнчә, көн саен 250–300 тонна сөт эшкәртү өчен чимал бар. Район һәм республика җитәкчеләре дә бу фикерне хуплагач, җиң сызганып эшкә тотындык, – ди яңа предприятиегә нигез салучыларның берсе эшмәкәр Марсель Хәкимов.

«Искегә тисәң, исең китәр» дигән гыйбарәне ул чакларда еш искә алганнар. Ни өчен дигәндә, шактый еллар элек банкротлыкка чыккан предприятиенең инде диварлары гына калган була. Барлык төр коммуникация эшләрен яңадан башкарып чыгарга туры килә. Заманча технологияләргә нигезләнгән яңа җиһазларны урнаштыру, эшләтә башлау өчен генә дә 160 миллион сумлык чыгымнарга барырга туры килә.

Югыйсә әллә ни күп вакыт та узмаган. Ел ярым эчендә предприятие сафка басып, шушы көннәрдә беренче продукциясен бирә башлаган.

Автор фотосы

Мондый үзгәрешләргә район хуҗалыклары белән беррәттән, Төрнәс авылы халкы да бик шат. Ни өчен дигәндә, сөт эшкәртү предприятиесе бүген үк инде авылның утыздан артык кешесен эшле иткән. Элек кая барып, ничек көн күрергә белми аптыраган кешеләр өчен моннан да зуррак шатлыкның булуы мөмкин түгелдер.

Биредә эшләүче Альберт Дилмөхәммәтов сүзләренә караганда, предприятиедә эшләр өчен барлык шартлар тудырылган. Хезмәт хаклары да яхшы. Эш булгач, кайчандыр авылдан киткәннәр дә кире кайта башлаган.

Белгечләрне дә читтән эзләп йөрми алар. Үзләрендә әзерләргә тырышалар. Предприятие әле башлангыч чорында гына булса да, тирә-юньдәге хуҗалыклардан көн саен 40–50 тонна сөт кабул итә. Әлегә төрле сөт продуктлары җитештерәләр. Якын киләчәктә тәүлегенә 120 тонна сөт эшкәртә башлаячакбыз, диләр.

Сөт эшкәртү предприятиесе инвесторлары Александр Иванов һәм Марсель Хәкимовның планнары тагын да зурдан. Киләчәктә район хуҗалыкларында җитештерелгән сөтне тулысынча үзләре эшкәртүне максат итеп куйганнар. Эшләүчеләр саны, бүгенгедән өч тапкыр артып, 90 кешегә җитәчәк, диләр.

Камил СӘГЪДӘТШИН

ТАТАР ТЕЛЕ: ДӘРЕСМЕ, УЕНМЫ?

Мәктәпләрдә татар телен кызыксындырып укыту алымнарын таптыкмы әле? Казанда яңа уку елында ачылган «Унбер» мәктәбендә татар телен укытуда заманча һәм нәтиҗәле ысуллар турында сөйләштеләр. Бу туган тел укытучылары өчен оештырылган очрашуларның икенчесе иде. Дәресләр ничек үзгәргән?

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Быел татар теле укытучыларына зур игътибар юнәлтергә тырышабыз. Беренче семинарда 300ләп кеше катнашса, бу юлы да шуның кадәр укытучы килде. Татар телен балаларны кызыксындырып укытырга кирәклеген беләбез. Шуңа күрә кызыклы, көчле белгечләрне чакырдык. Укытучыларга файдалы булыр дип уйлыйбыз. Казан мәктәпләрендә укучыларның 50 проценттан артыгы татар телен туган тел буларак өйрәнә, – диде Казан мәгариф идарәсе башлыгы Ирек Ризванов.

«Унбер» лицее директоры Алмаз Хәмидуллин әйтүенчә, мәктәптә мавыктыргыч татар теле дәресләренә кызыгып, берничә дистә укучы туган тел өйрәнү турында гаризаларын кабат язган, урыс теле урынына татар телен сайлаганнар.

Токио чит телләр университеты аспиранты Юто Һишияма видеоформатта университетта татар телен укыту тәҗрибәсе белән таныштырды. Юто татар теле буенча халыкара олимпиадада гран-при отып, КФУда магистратурада укып, Токио университетында татар телен өйрәтә. Студентларны татар теле, татар дөньясы белән кызыксындыра.

Казандагы «Бала-сити» мөгаллиме, мәктәпнең халыкара уку программасы җитәкчесе Шеймус Колл да инглиз телен ничек өйрәтүе турында сөйләде. Әгәр бала инглиз телен сүз, ишарә яки рәсемнәр белән күрсәткәндә аңламаса, укытучы русча сөйләшүче укытучыны чакырырга мөмкин. Укытучы дәрестә укытучы түгел, ярдәмче ролен башкара. Кыскасы, дәреснең күп өлешен укучылар алып бара.

«Сәлам» дәреслекләре турында дәреслек авторларының берсе, Казанда татар теле һәм әдәбияты укытучы Эльвира Марковадан сораштык.

– Бу дәреслек аралашуга нигезләнеп төзелгән. Без кагыйдәләрне генә өйрәтмибез. Билгеле, аннан башка да булмый. Әмма аны әзер сөйләм калыпларына нигезләнеп төзибез. Башлангыч сыйныфларда, аңлатып тормыйча, әзер калып бирә идек. Урта сыйныфларда кагыйдәне җиңелчә өйрәтәбез. Дәрес ахырында укучы үткән тема буенча сөйли белергә тиеш. Укыту алымнарын инглиз теленекенә яраклаштырдык. Моңа кадәр җөмлә төзетәләр, әмма аралашу юк иде. Әйдәгез, диалогны укыгыз да сөйләгез, дип кенә булмый. Башта сүзләрне өйрәнәсең. Шулай ук уен аша да мөмкин, укучыларны төрле ситуацияләрдә калдырып карыйсың. Шуннан чыгып, аралашу да үзгәрә. Укытучы бары татар телендә генә сөйли. Укучы 9 нчы сыйныфка кадәр татар телендә ипи-тозлык булса да сөйләшә белергә тиеш. Артыгын таләп итеп булмый. Атнасына ике дәрес белән нәрсә генә өйрәнәсең? – ди Эльвира Маркова.

Казандагы 117 мәктәпнең татар теле һәм әдәбияты укытучысы, Мещерякова системасы тьюторы Фәния Гаязова да үз дәресеннән мисаллар китерде.

– Укучыда татар теленә карата кызыксыну уяту барыбызны да борчый. Мин биш ел инде Мещерякова системасын кулланып укытам. Ул тулысынча аралашуга нигезләнгән. Методик кулланма, эш дәфтәрләре, электрон һәм күрсәтмә әсбаплар, схемалар, күп. Укыта башлаганда, Валерия Мещерякова безне сәхнәгә чыгарды да уен уйнатты. Шулкадәр кызык итеп уйната, уйныйсы да килә, әмма телне белмәү кыенлык тудырды. Безнең каршыда да шундый ук балалар. Кайберләре татарча бер сүз дә әйтә белми. Без алардан нәрсә булса да таләп итәбез. Шулай итеп булган кызыксынуны да киметергә, туктатырга мөмкинбез. Дәрестә татарча гына сөйләшергә тырышам. Кул хәрәкәтләре, уен, җыр-биюләр аша аңлатам. Дәрестәге уеннарны, җырларны видеога төшереп, әти-әниләргә дә җибәрәбез. Алар балаларының татар телен өйрәнүен күргәч, бик нык сөенәләр, – диде Фәния Гаязова.

Башка районнарда рус телле мәктәпләрдә татарчага ничек өйрәтәләр икән? Бу хакта Арча районы Иске Чүриле мәктәбенең татар теле укытучысы Ләйсән Вәлиевадан кызыксындык.

– Безнең мәктәп – рус мәктәбе. Арада мари, таҗик, үзбәк, әрмән балалары да укый. Татар телен ике төркемгә бүлеп өйрәтәбез. Рус балалары арасында да тел белән кызыксынучылар шактый. Безнең максат – укучыларны аралашырга өйрәтү. Татар теле аларга чит теле булуын онытмаска кирәк. Татар телендә узучы чараларда катнаштырабыз, олимпиадаларга алып барабыз. Алар алдынгы урыннар яулый. Телне өйрәтү өчен мөмкинлекләр күп. Дәреслекләр бик уңайлы, электрон әсбаплар да бар. Безгә бары өйрәтергә генә кирәк. Инглиз теле укыту методикасына таянып эшлибез. Баштагы елларда аның методикасын белеп бетермәгәнбез. Кагыйдә өйрәтү белән шөгыльләнгәнбез дип уйлыйм. «Сәлам» дәреслеге бик кызык. Төрле уеннар уйныйбыз. Укучылар табиб, кибетче дә була. Сөйләшергә шулай өйрәнәләр, – диде Ләйсән Вәлиева.

Татар телен өйрәтү буенча кызыксындыру алымнарын эзләү яхшы анысы. Укытучылар дәресне яраттыра белгәндә, башка милләт балалары да, татарча белмәгән татар балалары да татар телен теләп өйрәнә башлар, бәлкем. Тик бу урында «Нигә мәктәптәге математика, физика яки башка фәннәрне дә кызыклы итеп өйрәтү турында баш ватмыйлар икән?» дигән сорау туа. Математиканы уйнап өйрәтеп карыйк әле, ә? Бәлкем, алай кызыграк булыр?

Сәрия МИФТАХОВА

Ябык ишекләр

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Ләкин кондукторлар һәм пассажирларның барысы да бер түгел шул. Әйтик, Казанда дүшәмбе көнне төш вакытына җәмәгать транспортыннан 800гә якын кешене төшерергә мәҗбүр булганнар. Ә бер пассажир код күрсәтүне сораган кондукторның йөзенә газ баллонынннан сиптергән. Бу хәбәрне Сергей Темляков та раслады. Сүз уңаеннан, хокук сакчылары мондый очракларның һәрберсен тикшереп барачак.

Дөрес, бу яңалыкны тынычрак кабул итүчеләр дә җитәрлек. «Автобуска утыртмаячакларын белә торып, ник тукталышка чыгарга? Алдан кисәттеләр бит инде. Иң ачуны китергәне: бөтен үчне кондукторлардан алалар. Аларның ни гаебе бар? Хәер, үзе турында уйламаган кеше ник башкалар турында кайгыртсын ул? Мин прививканы әле яз көне үк кадаттым. Шулай буласын белдем. Сәламәтлек кирелектән мөһимрәк», – ди автобуска керергә чират көткән апаларның берсе.

Җәмәгать транспортында башы иң нык буталган кешеләр транспорт картасыннан файдалана алмаучы өлкән пассажирлар булды. Һәрхәлдә, без йөргән маршрутларда шулай иде. Билгеле булганча, 60 яшьтән өлкән пассажирларның QR-коды яисә «медотвод»ы булмаса, аларның транспорт карталары вакытлыча эшләмәячәк. Иртәнге якта бер әбекәй белән сөйләштек. «Өйдә утыра алмыйм мин. Балаларым янына барырга кирәк. Хәзер мин шуның өчен үз кесәмнән акча түләргә тиешме?» – диде ул. «Код яисә белешмәгез юкмыни?» – дип сорагач: «Вакцина ясатырга ярамый миңа, ә аны раслаучы кәгазьне һаман бирмиләр. Аптыраган инде», – дип күрсәнде. Аннан юл буе үзенең яшьтәше белән «шушы коронавирус дигән зәхмәт»не сүкте.

Җәмәгать транспортында QR-код тикшерү кагыйдәсе беренче булып Татарстанда керде. Шуңа күрә бездәге хәлләрне башкалар да күзәтә. Бу уңайдан Россия Президенты Владимир Путинның матбугат сәркатибе Дмитрий Песков әйтүенчә, яңалыкны керткәндә мәшәкатьләрсез генә булмый.

– Бу очракта Татарстан пандемия фонында һәр төбәккә бирелгән вәкаләтләрдән файдалана. Кешеләр шуны аңласын иде: боларның барысы да аларның сәламәтлеген саклау максатыннан эшләнә, – диде ул.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Илдар Мөхәммәтҗанов

Татарстанның Сәламәтлек саклау министрлыгы хәбәр иткәнчә, Медицина өлкәсендәге мәгълүмат һәм аналитика үзәгендә җәмәгать транспорты өчен QR-код алу мәсьәләләре буенча «кайнар линия» эшләячәк. Әлеге мәсьәләгә кагылышлы сораулар буенча **+7 (919) 693-05-43** номерына шалтыратырга мөмкин. Сорауларны **8(843) 291-90-13** номеры аша Татарстанның Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына да юлларга була.

МАШИНА БУРЫЧ ҖЫЙМАСЫН БАШЫМА

40 МЕҢНӘН АРТЫК КЕШЕ ТРАНСПОРТ САЛЫМЫНА ТАШЛАМАЛАРДАН ФАЙДАЛАНГАН

Барлык күчемле һәм күчемсез милек хуҗаларына 2020 ел өчен салым хатларын җибәрү тәмамланган. Быел республикада яшәүчеләргә җәмгысы 2 миллион 157 мең салым хаты юлланган. Исәпләнгән салымның гомуми күләме – 8 миллиард 100 миллион сум, шуның 4,5 миллиард сумы – транспорт салымы.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Транспорт салымын үз исеменә транспорт чарасы теркәлгән кешеләр түли. Салым күләменә салым ставкасы, бер календарь елы эчендә транспортка хуҗа булу вакытына бәйле коэффициент, өч миллион сумнан артыграк бәядәге җиңел автомобильләргә артыклык коэффициенты, ташламаларга хокук йогынты ясый.

Салым хатында транспорт салымы күләменең дөрес күрсәтелү-күрсәтелмәвен тикшерү өчен «Калькулятор транспортного налога ФЛ» хезмәтеннән файдаланырга мөмкин. Мәсәлән, двигателенең егәрлеге 107 ат көченә тигез булган машинага транспорт салымы күләмен исәпләп чыгарырга кирәк ди. Татарстанда двигателенең егәрлеге 100 ат көченнән 150 ат көченә кадәрге автомобильләргә салым ставкасы һәр ат көченә 35 сум тәшкил итә. Бер еллык салым күләмен билгеләү өчен, ставканы егәрлеккә тапкырларга кирәк. Бу очракта бер елга транспорт салымы күләме 3745 сум килеп чыга.

Ә инде бәясе 3 миллион сумнан артыграк кыйммәтле машиналарга транспорт салымы күләмен билгеләү өчен, ставканы егәрлеккә һәм артыклык коэффициентына тапкырлау шарт. Мондый автомобильләр исемлеге һәр ел саен 1 марттан да соңга калмыйча Россия Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының (minpromtorg.gov.ru) һәм Россия Салым федераль хезмәтенең рәсми сайтларына (nalog.gov.ru) урнаштырыла.

Федераль һәм төбәк законнары нигезендә, транспорт салымы буенча ташламалар күздә тотылган. Әйтик, Россия Салым кодексы буенча, инвалидлар өчен махсус җиһазланылган яки социаль яклау хезмәте аша алынган җиңел автомобильләргә, авыл хуҗалыгы җитештерүчеләренең махсус техникасына, егәрлеге 5 ат көченә кадәрге көймәләргә салым салынмый. Моннан тыш эзләүдәге транспорт чарасына, хуҗасына кайтарылган айга кадәр, салым салынмый. Эзләү туктатылып, машина табылмаган очракта, салым түләргә кирәк булмаячак, дигән сүз.

«Транспорт салымы турында» 29 ноябрь, 2002 ел, № 24-ТРЗ Татарстан Республикасы законы нигезендә, гражданнарның кайбер категорияләренә (боларга двигателенең егәрлеге 100 ат көченә кадәрге машина хуҗалары – I һәм II төркем инвалидлар керә) салым ташламалары күздә тотылган. Шул ук вакытта ташламалы салымны 1 автомобильгә генә түләргә мөмкин. 2022 елга салым түләү өчен гамәлдәге ташламаларның тулы исемлеге белән «Справочная информация о ставках и льготах по имущественным налогам» хезмәте аша танышырга мөмкин.

Быел Татарстанда 40 меңнән артык кеше транспорт салымын ташламалы нигездә түләгән. Ташламаның гомуми күләме 107 миллион сум тәшкил иткән. Салым федераль хезмәтенең Татарстан буенча идарәсе республикада яшәүчеләргә 2020 ел өчен милек салымын 1 декабрьгә кадәр түләү зарурилыгы турында тагын бер кат искәртә.

Эт өрер, авыру йөрер

Татарстан хайваннар арасында таралган куркыныч авырулар буенча чагыштырмача имин төбәк булып санала. Ә менә котыру авырулары әледән-әле республиканың төрле районнарында чыккалап тора.

Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе белгечләре әйтүенчә, ел башыннан республикада котыру авыруының 21 очрагы теркәлгән. Бүгенгә булган мәгълүматлар буенча, Түбән Кама районының Смыловка, Алексеевск районының Войкино, Балтач районының Кариле, Мамадыш районының Иске Завод, Тукай районының Түбән Суыксу авылларында, Алабуга шәһәрендә карантин игълан ителгән.

– Аларның күпчелегендә этләрнең авыру йоктыруы ачыкланды. Ике авылда песиләр авырганлыгы билгеле булды. Гадәттә төлкеләр авыру тарата торган иде. Соңгы очракларда әлеге җәнлеккә бәйле вакыйгалар тынып тора, – ди белгечләр.

Тукай районының Түбән Суыксу авылында шәхси хуҗалыкта асралган этнең авыру ияртүкәнлеге ачыкланган. Әлеге авылга беренче чиратта авыру йоктыру куркынычы зур булган хайваннарны алып керү һәм алып чыгу тыелган. Шулай ук хайваннарны дәвалау да ярамый. Авыл янында ике чакрым радиуста ярминкәләр һәм күргәзмәләр оештыру шулай ук тыела. Билгеле булганча, карантин гадәттә котыру авыруы белән авырган соңгы хайван юк ителгәннән соң ике ай узгач, юкка чыгарыла.

Баш ветеринария идарәсе белгечләре сүзләренә караганда, әлеге авыру кабынып ала да сүлпәнәя.

– Гадәттә уңыш күп булган елны күсе-тычканнар арта. Димәк, бүре, төлкеләргә дә азык мулдан дигән сүз, – дип аңлата белгечләр. – Ә төлкеләр Татарстанда котыру авыруын иң күп таратучылар булып тора. Быел бу проблема кискен түгел, шулай да профилактика чараларын һәрдаим башкарып торырга кирәк. Шуңа карамастан, билгеле бер җирлектә бу йогышлы авыру очраштыргалый.

Баш ветеринария идарәсенең хайваннарның йогышлы авырулары һәм эпизоотиягә каршы чаралар бүлеге җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Елена Ильина сүзләренә караганда, котыру авыруының кешеләргә дә күчү куркынычы бар. Ул шуның белән куркыныч та. Авыру хәтта кеше үлеменә дә китерергә мөмкин. «Медицина ничек кенә алга китсә дә, котыру авыруына каршы нәтиҗәле дәвалану уйлап табылмаган әле», – ди ул. Шуңа күрә саклану чараларын күрергә кирәк.

– Ул авыру хайван кешене тешләгән, тырнаган очракта йогарга мөмкин. Шулай ук котырган хайванның селәгәе тән тиресенә, күзгә, авызга, борынга тигән очракта да күчүе бар, – дип аңлата Елена Ильина.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Язманы газетага әзерләгән вакытта Тукай районында кош гриппы таралганлыгы билгеле булды. Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе хәбәр итүенчә, берничә хуҗалыктан кала, районда барлык йорт кошы юк ителәчәк. Эдуард Фролов фермер хуҗалыгында 42 мең баш бытбылдык, 10 мең бытбылдык чебие, 171 килограмм кош ите һәм 40 мең бытбылдык йомыркасы юк ителгән. Шулай ук Калмаш, Югары Байлар авылларында һәм Яңа бистәдә барлыгы 1470 тавык, 9 үрдәк, 7 мисыр тавыгы, 1068 каз яндырылган. Әлеге вакытта авыру килеп чыгу сәбәпләре ачыкланмаган. Тикшерү бара.

КАРАНТИН ВАКЫТЫНДА НӘРСӘ ЭШЛӘРГӘ ЯРАМЫЙ?

Ит сату, аны һәм эшкәртелмәгән тирене әлеге территориядән алып чыгу, сәламәт сыерларның сөтен кайнатмыйча эчү һәм авыру терлекләрне сую тыела.

КЫРГЫЙ ЯКИ ХУҖАСЫЗ ЭТ ТЕШЛӘГӘН ОЧРАКТА НИШЛӘРГӘ?

- Яраны юарга һәм спирт яки антисептик белән эшкәртергә.
- Тиз арада табибка мөрәҗәгать итәргә.
- Кирәк булса, табиб прививка курсын билгеләячәк. Прививканы 3–6 тапкыр 90 көн дәвамында кадыйлар.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Спорт

МОЗЯКИННЫ КУЫП ТОТА АЛМАЯЧАК

«Ак барс» капитаны Данис Зарипов Казан командасы өчен 900 нче очрашуын уздырды. Ул гына да түгел, 40 яшьлек һөҗүмче «Торпедо»га каршы узган уенда нәтиҗәгә ирешеп, ил чемпионатларында иң күп алка керткән уенчылар исемлегендә икенче урынга чыкты.

Данис Зарипов Казанда 2001 елда уйный башлады. Казан командасы составында суперлигада – 412, ә КХЛда 488 очрашуда бозга чыкты. Россия чемпионы булды (2006 ел) һәм өч мәртәбә Гагарин Кубогы иясе булып танылды (2009, 2010, 2018). Бер команда өчен уйнаган матчлар саны буенча ул «Локомотив» сакчысы Сергей Жуков (959 очрашу) һәм «Металлург» сакчысы Евгений Бирюковтан (928) гына калыша. «Мондый күрсәткечләр теләсә кайсы уенчы өчен әһәмиятле. 900 очрашу – минем тырышлыгым, теләгем һәм тормышымдагы төп максатымның нәтиҗәсе», – ди Данис Зарипов.

«Ак барс» капитаны 429 алканың 290ын – «Ак барс»та, 124ен – «Металлург»та, 15ен исә «Мечел»да уйнаганда керткән. Шулай итеп, ул легендар Борис Михайловны (428) узып китте. Хәзер Данис Зарипов үзенең күптәнге дусты, быел җәй карьерасын тәмамлаган Сергей Мозякиннан гына калыша. Аның 556 алкасы бар. «Борис Михайловтан аны узып киткәнем өчен гафу үтенәм. Ә менә Сергей Мозякинны куып тоту мөмкин эш түгел. Үзем гаепле, димәк, аңа пасларны күп биргәнмен. Шулай да икенче урынга чыга алуым өчен бик сөенәм», – ди соңгы сезонын уздыручы һөҗүмче.

ДАНИЯНЕҢ ИКЕ ЕГЕТЕ ДӘ ШӘП

«Сочи»га каршы узган очрашуда җиңү яулый алган «Рубин»ның бу матчта төп геройлары булып Дания уенчылары танылды. Өч очко Казан командасына премьер-лиганың беренче өлешен 8 нче урында тәмамларга мөмкинлек бирде.

15 нче турның соңгы очрашуында өстенлек күбрәк «Сочи» уенчылары ягында булды. Беренче тайм уртасында аларның алга чыгуы гаҗәп тә түгел. Әмма берничә минуттан ярымсакчы Оливер Абильдгор Казан командасы өчен беренче тубын кертте һәм исәпне тигезли алды. Дания футболчысы моның белән генә туктап калмады һәм икенче таймда, юк урында икенче кисәтүен алып, уен кырыннан куылды. Ә бит бу вакыйгага ике минут кала «Сочи» уенчысына да шундый ук җәза бирелгән иде. Нәтиҗәдә «Рубин»ның бер кешегә күбрәк уйнау өстенлеге юкка чыкты. Әмма Казан командасында Даниядән килгән тагын бер уенчы бар. 79 нчы минутта Андрес Дрейер озак итеп аяк киемен алмаштырды, ә ике минуттан командасына җиңү китергән тупны кертте. Бу – аның «Рубин»дагы бишенче голы. Алтынчысы да булырга мөмкин иде. Әмма хөкемдар матчның соңгы минутында кергән тупны санамады.

	команда	очко
1	Зенит	33
2	Динамо	29
3	Сочи	27
4	Локомотив	25
5	Краснодар	24
6	ЦСКА	24
7	Крылья Советов	23
8	Рубин	22
9	Ахмат	21
10	Спартак	19
11	Ростов	17
12	Уфа	15
13	Нижний Новгород	14
14	Химки	13
15	Арсенал	13
16	Урал	12

rubin-kazan.ru

Белми калмагыз!

«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»ГА ЯЗЫЛУЧЫГА – МИНИ-ТРАКТОР

БҮЛӘКНЕ АЛУ ШАРТЛАРЫ

1 2022 елның беренче яртыеллыгына 6 айга «Ватаным Татарстан» газетасына язылырга.

2 Язылу квитанциясен безгә җибәрергә: «Ватсап» (89179270040) яки почта аша (420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт, «ВТ» газетасы редакциясе), яки электрон адреска (info@vatantat.ru).

БЕЛЕШМӘЛӘР ӨЧЕН ТЕЛЕФОН: 8-917-927-00-40

Җиңүче жирәбә юлы белән ачыкланачак. Квитанцияләр 2022 елның 16 гыйнварына кадәр кабул ителә, жирәбә 20 гыйнвар көнне үткәреләчәк.

Акцияне оештыручы: «Ватаным Татарстан» газетасы ДБУ, акцияне уздыру вакыты 2021 елның 1 ноябреннән 2022 елның 15 февраленә кадәр. Тулырак мәгълүмат vatantat.ru сайтында.

УРАЛЕЦ ТОРГОВЫЙ ДОМ МЫ ПРОДАЁМ НАДЁЖНОСТЬ

АКЦИЯНЕҢ ИГАНӘЧЕСЕ – «УРАЛЕЦ» СӘҮДӘ ЙОРТЫ

- ✓ мини-тракторлар;
- ✓ барлык төр тракторлар өчен запас частьлар;
- ✓ җир эшкәртү, чәчү, җыйнау өчен асылмалы җиһазлар.

Казан ш., Мамадыш тракты, 35А; Чаллы ш., Казан проспекты, 252/1; Әлмәт ш., Советская урамы, 42А.

ТЕЛЕФОННАР: 8-927-465-12-94, 8-987-931-55-50

ГАЗЕТАГА ЯЗЫЛУ ЫСУЛЛАРЫ



1 ПОЧТА БҮЛЕКЧӘЛӘРЕНДӘ

2 ОНЛАЙН: vatantat.ru сайтындагы сылтама аша газетага язылу бик уңайлы һәм тиз. Программа үзе адымлап алып бара.

Әлеге QR-код ярдәмендә телефон аша газетага язылырга һәм акча түләргә мөмкин.

2022 елның беренче яртыеллыгы өчен 6 айга язылу бәяләре

П2435 атнага бер, җомга килә	465 сум	П2409 Сишәмбе, чәршәмбе, җомга, шимбә килә	1000,92 сум

Реклама 16+

2021 – ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ

БӨТЕНЛЕГЕБЕЗ – ТӨРЛЕЛЕКТӘ

Республикабызда яшәп, үз милләтен ихластан яратучы, башкаларга да ихтирам белән караучы милләт вәкилләренең тормыш-көнкүреше белән таныштыруны дәвам иттерәбез.

«МАРИ МӘДӘНИЯТЕНӘ МӘХӘББӘТНЕ ӘБИЕМ ТӘРБИЯЛӘДЕ»

Мари кызы Мария Кибаева «Инстаграм»да төрле милләтләрнең гореф-гадәтләре, бәйрәмнәре белән таныштырып бара. Кем соң ул сөйкемле, шат күңелле Мария?

Пермь якларында туган ул. Мәктәптә баян сыйныфын тәмамлаган. Беренче мөгаллимнәре – Юрий Евдокимов (Мари Иле дәүләт гимны авторы. – **Ред.**), Светлана Евдокимова. Мәктәптән соң Пермь краеның мәдәният һәм сәнгать көллиятенә укырга кергән. Көллияттә укыганда ук, төрле тәбәкләргә, чит илләргә гастрольгә йөри башлаган. Иң истә калганы Амстердамга сәяхәт икән. Вокаль бәйгедә бик күп бүләкләр, гран-при алып кайтканнар. Мария укуын алга таба дәвам иттерә. Казан дәүләт мәдәният институтында халык хоры белгечлеген ала. Мария бүген – Татарстан Халыклар дуслыгы йортында милләтләр белән эшләү буенча белгеч һәм солист, бөтенроссия һәм халыкара конкурслар лауреаты.

– Төрле милләтләр белән эшләсәм дә, үз халкымны онытмыйм. Мари җырларына, мәдәниятенә мәхәббәтне әбием тәрбияләде. Мине төрле концертларга йөртә иде, – дип сөйләде Мария. – Автономия – шәһәрдәге, республикадагы марилар белән аралашу өчен бер мәйданчык. Олыларны – «Озан мари», яшьләрне исә «Лай Мардеж» фольклор ансамбльләре берләштерә. «Шорыкйол», «Уярня» бәйрәмнәрен уздырабыз. Бүген аз санлы халыкларның мәдәниятен өйрәнү бик актуаль түгел. Шулай да үз милләтен хөрмәт иткән, әби-бабайлары каршында җаваплылык тойганнар буыннан-буынга күчеп килгән традицияләрне сакларга тырыша. Үз телемне бик яхшы беләм. Бервакытта да мари булуымнан оялмыйм. Нәселемдә дә барысы – марилар. Мари мәдәниятен, телен саклаучыларга рәхмәтемне белдерәсем килә. Кибеттә яки урамда марича ишетүнең нинди рәхәт икәнен белсәгез иде!

«КАЗАН – МИНЕМ ӨЧЕН БИК ЯКЫН ҖИР»

Җәйге Универсиада ярышларын карарга дип Казанга килгән егет, шәһәрне ошатып, биредә яшәп кала. Казан үзенең матурлыгы, чисталыгы, яхшы күңелле кешеләре белән әсир итә аны. Сираж Джавадбеков Татарстанның Дагыстан белән охшаш якларын күрә.

– Биредә мин әти-әнигә ихтирам, өлкәннәргә хөрмәт хисе көчле булуын тойдым. Без дә бит нәкъ шулай тәрбияләнгән. Шуңа да мин, монда килгәч, чит җиргә түгел, үз ягыма кайткандай булдым, – ди Сираж.

Казанда яши башлагач, егет бию ансамбле булдыру турында уйлана. Үзе хореограф буларак, янына бии белгән егет-кызларны җыя башлый. Баштарак җиңел булмый. Әмма, үзе әйтмешли, авырлык артыннан җиңеллек тә килә. Әкренләп биючеләр табыла. Сираж үзе дә ул чакларны искә алып: «Казанда мин тормыш мәктәбе уздым», – ди.

– Үзем кечкенәдән биюгә йөрдем. Мине ул түгәрәккә бабам илткән иде. Әле дә хәтеремдә: мине үземнән 11 яшькә зуррак егет өйрәтте. Карап торышка яшь кенә, әмма бик тәҗрибәле иде ул. Бию серләренә төшендерде. Мин анда йөреп, күп әйбергә өйрәндем. Казанга килеп эшли башлавымда укытучымның да өлеше зур, – ди ул. – Башта җиңел булмады. Без кечкенә адымнар белән алга бардык. Башта бер кеше, аннан икенчесе килде. Хәзер инде «KAVKAZ STILE» халык бию ансамбле эшли башлаганга 7 ел була. Безнең ансамбльдә 70тән артык кеше бар. «Дагестан» дигән балалар бию коллективы эшләп килә. Бүгенге уңышыбыз, халыкның безне яратуы ул – зур тырышлык һәм сабырлык нәтиҗәсе. Чит җирдә үз юлымны табуым белән мин бәхетле. Коллективыма мең рәхмәт. Аллаһы Тәгаләгә мине тудырган әти-әнием өчен рәхмәт укыйм.

Сираж әлегә өйләнмәгән. Әмма татар кызларын ошатуын яшерми. Казанда яшәп калырга тели.

– Бу шәһәр – минем өчен бик якын җир. Мин аңа гашыйк. Хыялларым күп минем. Дәүләт ансамбле статусын алсак иде. Бер карасаң, без бит Татарстан халкы өчен дип эшлибез. Республикадагы милләтләр дуслыгы сагында торабыз. Ансамблебезнең зур составлы булуын шулкадәр телим, – ди ул. – Миңа татар теле бик ошый. Әкрен генә сөйләшсәләр, сүзләрне аңлыйм. Үзем дә күп кенә чараларда татарча сәламләргә, кайбер сүзләрне әйтергә тырышам. Минем өчен иң мөһиме – кешенең милләте түгел, күңел чисталыгы. Әгәр без бер-беребезгә яхшы мөнәсәбәттә булабыз икән, әлбәттә, Татарстанда халыклар дуслыгы тагын да ныгыячак кына.

«ПЕШКӘН КУКУРУЗ САТЫП, АКЧА ҖЫЙДЫК»

Хуссам Мөхәммәд Татарстанга 1999 елда килә. Ливан университетында биология факультетының 1 курсын тәмамлагач, очраклы рәвештә бер белдерү күреп ала ул. Россиядә белем алу мөмкинлеге бар икән. Җитмәсә, уку бәясе дә арзан. Әти-әнисенең матди чыгымнарын киметү ниятеннән, Хуссам Татарстанга юл тота.

– Башта кайсы шәһәргә җибәрәселәрен белмәдем. Казанга эләгүемә бик сөендем. Бу шәһәр мине хәләл җефетем белән кавыштырды. Регина белән беренче курста укыганда ук бер партада утырдык. Хәзер инде йөрәгебезне биреп эшләгән уртак эшебез бар. Икебез дә – теш табиблары, 4 балабыз үсә, – ди Хуссам.

Казанга күченгән вакытта җиңел булмаса да, Хуссам зарланмый. Киресенчә, тулай торакта яши башлауларын кызык итеп искә ала. «Бер катка бер бәдрәф, бер аш бүлмәсе булуын әле дә онытмадым», – ди. Студент елларындагы тормыш бик чыныктыра аны. Салкын кышны күреп тә исе китә. Бервакыт кышын кояшка алданып, яланбаш чыгып китәләр. Чатнама суык көн була ул. Читтән килгән студентларга кояш булгач, башкасы мөһим түгел. Әле ярый яшьләрне вакытында кисәтеп өлгерәләр.

Казанда яши башлавына 20 елдан артык вакыт узып киткән. Башта хастаханәләрдә эшләгән, аннары үз клиникасын ачкан. Дөрес, балачак хыялы хирург эше белән бәйле булган аның.

– «Табиб булсаң, мин сиңа матур кабинет ясап бирермен». Мин кечкенә вакытта әтием шулай дип әйтә иде. Әнә шул сүзләр миңа көч өстәде. Хирург түгел, теш табибы булуымны сизми дә калдым. Үз клиникабызны ачар өчен, ислам дине буенча, безгә кредит алырга ярамый. Шуңа күрә туңдырма һәм пешкән кукуруз сатып, акча җыйдык, – ди ул.

Хуссам – күпбалалы гаиләдән. Алар барлыгы 16 туган. Бертуганнары Кытай, Төркия, Мисырда яши. Татарстанга килгәч, бездәге кунак кабул итү гаҗәпләндергән аны. Баксаң, Ливанда килгән кешене табын корып каршы алу гадәте юк икән. Кеше килү гаилә өчен үзе зур бәйрәм санала. Казанда исә һәркемне чәй өстәле әзерләп каршы алырга өйрәнгән Хуссам. Гаилә димәктән, чит ил егетен Регинаның әти-әнисе дә бик яратып кабул итә. Сәбәбе дә бар. Регинаның апасы төрек егетенә кияүгә чыккан. «Гаиләбездә ислам дине кушканча яшибез. Балалар төрле телләр белә. Берсен дә мәҗбүриләмибез. Үзләре өйрәнә. Мин дә, кирәк булгач, рус телендә сөйләшергә өйрәндем бит, – ди Хуссам. – Балаларымны рәхмәтле булырга өйрәтәм. Яшәгән җиребезне яратабыз. Биредә мин белем алдым, гаилә кордым, эшле булдым. Балаларым өчен җаным тыныч. Шуңа да бу җиргә рәхмәттән башка сүзем юк».

КАЗ КАУРЫЕН ЮЛГА СИБӘЛӘР

Зәй районының Имәнлебаш мәдәният йорты «Әйлән-бәйлән» түгәрәк уен фестивалендә катнашкан. Ул халкыбызның онытылып барган гореф-гадәтләрен, йолаларын, җыр-биюләрен, такмакларын түгәрәк уеннары аша заманчалаштырып, яшь буынга җиткерүне күздә тота.

– Авылда казлар күп асрыйлар. Без дә быел 150 бәбкә үстердек. «Каз өмәсе» бәйрәмен район халкына дүрт мәртәбә күрсәткән бар иде инде. Бу юлы «Каз канаты сыдыру» йоласын сәхнәләштердек. Бу йола безнең авылда борынгыча сакланган. Бәйрәм өмә җырлары, табышмаклар, җырлы-биюле уеннар, тизәйткечләр белән үрелеп барды. Авылыбыз яшьләре чын артистларча чыгыш ясады. Коймак пешереп, тәмләп чәй эчтек, – ди мәдәният йорты җитәкчесе Энҗе Әхмәтҗанова.

Сыдырылган канатларны соңыннан казлар йөри торган урыннарга сибәләр икән. Монысы – башка елларда казлар күп булсын өчен. Каурыйлардан май канаты ясыйлар, мендәрләр тутыралар.

Сәхифәне Гөлгенә ШИҺАПОВА, Сәрия МИФТАХОВА әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар: ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.

Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7404 данә
Гомуми тираж – 17211 данә

Газетага сертификат бирелде

Заказ 370

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+